Республика Татарстан

Менделеевск муниципаль районы башлыгы

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башлыгы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

____12.02.2026_____ Менделеевск шәһәре № ____6_____

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм мәсьәләләре буенча комиссия төзү турында

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына нәтиҗәле социаль ярдәмне һәм адреслы ярдәмне тәэмин итү максатларында, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының ««Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләргә, затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына өстәмә социаль гарантияләр турында» 2022 елның 5 мартындагы 98 номерлы Указы нигезендә, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү мәсьәләләре буенча комиссия булдырырга.
2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча комиссия турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча комиссия составын расларга (2 нче кушымта).
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://mendeleevsk.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Искәндәров

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башлыгының 2026 елның 12 февралендәге
6 нчы номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында
махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү
комиссиясе турында нигезләмә

## 1 Гомуми нигезләмә

1.1 Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү мәсьәләләре буенча комиссия (алга таба - Комиссия) даими эшләүче киңәшмә һәм координация органы булып тора, ул махсус хәрби операциядә катнашучыларга (алга таба - МХО) һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм учреждениеләрнең килешенгән эшчәнлеген тәэмин итә.

1.2 Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасының законнарына һәм башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының муниципаль хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3 Комиссия эшчәнлеге законлылык, коллегиальлек, ачыклык һәм социаль гаделлек принципларына нигезләнә.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары

2.1. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

2.1.1 Җирле үзидарә органнары, хәрби комиссариат, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, оешмалар һәм учреждениеләрнең махсус хәрби операция катнашучыларына һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча нәтиҗәле хезмәттәшлекне оештыру.

2.1.2 Махсус хәрби операция катнашучылары һәм аларның гаиләләре әгъзаларының матди, психологик, медицина, хокукый һәм башка ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын карау.

2.1.3 Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә адреслы ярдәм күрсәтү эшен координацияләү.

2.1.4 Махсус хәрби операция катнашучылары өчен гуманитар ярдәм җыю һәм таратуны оештыру.

2.1.5 Махсус хәрби операция катнашучыларының һәм аларның гаиләләре әгъзаларының социаль-икътисади һәм хокукый хәлен мониторинглау.

2.1.6 Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләре очраша торган проблемаларны ачыклау һәм аларны чишү буенча тәкъдимнәр эшләү.

2.1.7 Махсус хәрби операция катнашучыларын һәм аларның гаиләләрен федераль, региональ һәм муниципаль дәрәҗәләрдә күрсәтелә торган ярдәм чаралары турында мәгълүмат белән тәэмин итү.

## 3 Комиссия функцияләре

3.1 Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

3.1.1 Махсус хәрби операция катнашучылары һәм аларның гаиләләре мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын карый, адреслы ярдәм күрсәтү турында карарлар кабул итә.

3.1.2 Махсус хәрби операция катнашучылары өчен гуманитар ярдәм җыю һәм тарату эшен оештыра һәм координацияли.

3.1.3 Махсус хәрби операция катнашучылары гаиләләренең көнкүреш проблемаларын хәл итүдә ярдәм күрсәтү эшен оештыра (торак ремонтлау, балаларны уку елына әзерләүдә ярдәм итү, эшкә урнашу мәсьәләләрен хәл итү һ.б.).

3.1.4 Гамәлдәге законнар нигезендә махсус хәрби операция катнашучыларына һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтүдә координация һәм ярдәм күрсәтү белән шөгыльләнә.

3.1.5 Махсус хәрби операция катнашучылары һәм аларның гаиләләре арасында ярдәм чаралары турында мәгълүмат-агарту эшен оештыра.

3.1.6 Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча җәмәгать оешмалары, волонтерлар берләшмәләре белән хезмәттәшлекне тәэмин итә.

3.1.7 Махсус хәрби операция зонасында һәлак булганнар өчен кабер ташлары урнаштыру мәсьәләләрен карый.

3.1.8 Гражданнарны ватанпәрвәрлек тәрбияләүгә һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларның батырлыгын искә алуны саклауга юнәлдерелгән чараларны оештыра һәм үткәрә.

## 4 Комиссия хокуклары

4.1 Үзенә йөкләнгән бурычларны һәм функцияләрне үтәү өчен Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1.1 Комиссия вәкаләтләренә караган мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм вазифаи затлардан кирәкле материаллар һәм мәгълүматларны соратып алу һәм билгеләнгән тәртиптә алу.

4.1.2 Комиссия вәкаләтләренә караган мәсьәләләр буенча үз утырышларына җирле үзидарә органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, оешмалар, җәмәгать берләшмәләре һәм башка кызыксынган затлар вәкилләрен чакырырга.

4.1.3 Махсус хәрби операция катнашучыларын һәм аларның гаиләләрен яклау мәсьәләләрен тиз арада хәл итү өчен эш төркемнәре булдыру.

4.1.4 Комиссия вәкаләтенә кергән мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр кертү.

## 5 Комиссия эшчәнлеген оештыру

5.1 Комиссияне Менделеевск муниципаль районы башлыгы - рәис җитәкли.

6. Комиссия рәисе:

- Комиссия эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә;
- комиссия утырышын уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгели;
- комиссия утырышының көн тәртибен раслый;
- комиссия утырышларында рәислек итә;
- комиссия утырышлары беркетмәләренә һәм башка документларына кул куя.

5.3 Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

8. Комиссия секретаре:

- комиссия утырышларын әзерләүне гамәлгә ашыра;
- комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра;
- комиссия әгъзаларын утырышның көне, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;
- комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;
- комиссиянең эш башкару эшләрен алып бара;
- Комиссия карарларының үтәлешен тикшерүне оештыра.

5.5 Комиссия әгъзалары:

- комиссия утырышларында катнашалар;
- комиссия утырышларында карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр;
- комиссия рәисе йөкләмәләрен үтиләр;
- комиссия карарларын үтәү эшендә катнашалар.

5.6 Комиссия утырышлары кирәк булган саен, ләкин айга бер тапкырдан да ким булмаганча үткәрелә. Кирәк булганда, чираттан тыш утырышлар үткәрелергә мөмкин.

5.7 Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының гомуми санынннан яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

5.8 Комиссия карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, комиссия утырышын алып баручы рәиснең тавышы хәлиткеч була.

5.9 Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга комиссия рәисе һәм секретаре кул куя.

21. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;
- утырышта катнашучы комиссия әгъзалары һәм чакырылган затлар исемлеге;
- утырышның көн тәртибе;
- көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча кабул ителгән карарлар;
- тавыш бирү нәтиҗәләре.

5.11 Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

## 7. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1 Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән кертелә.

6.2 Комиссия эшчәнлеге Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башлыгы карарына ярашлы туктатыла.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башлыгының 2026 елның 12 февралендәге
6 нчы номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында
махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм
мәсьәләләре буенча комиссия составы

Комиссия рәисе:

- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгы;

Комиссия рәисе урынбасары:

- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары;

Комиссия секретаре:

- Татарстан Республикасы Менделеевск районы Советының оештыру бүлеге башлыгы

Комиссия әгъзалары:

- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Менделеевск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча);
- Менделеевск районы хәрби комиссары (килешү буенча);
- «Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;
- Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе МКУ башлыгы;
- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе МКУ башлыгы;
- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы;
- «Менделеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча);
- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы;
- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча);
- Хәрби хәрәкәтләр ветераннары иҗтимагый оешмасы вәкиле (килешү буенча);
- «Җиңү волонтерлары» Бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең җирле бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча);

- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча);

- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ветераннар советы вәкиле (килешү буенча);

- Дин әһелләре вәкиле (килешү буенча);

- «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм күрсәтү дәүләт фондының социаль координаторы (килешү буенча);

- Пенсия һәм социаль иминият фондының район бүлеге начальнигы (килешү буенча);

- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы җитәкчесе (килешү буенча);

- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында «Беренчеләр хәрәкәте» җитәкчесе (килешү буенча);

- Ватан сугышчылары гаиләләре комитетының район штабы җитәкчесе (килешү буенча);

- Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте, шәһәр хуҗалыгы бүлеге начальнигы;

- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының ЗАГС бүлеге башлыгы;

- Менделеевск районы буенча ТР Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең бүлеге башлыгы (килешү буенча);

- Менделеевск муниципаль районында муниципаль психологик-педагогик хезмәт җитәкчесе (килешү буенча);

- Татарстан Республикасы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Менделеевск районы бүлеге башлыгы (килешү буенча).